**Казанский (Приволжский) федеральный университет**

**Олимпиада «МагистриУм»**

**2021-2022 учебный год**

**Институт Филологии и межкультурной коммуникации**

**Профиль: Теория и методика преподавания дисциплин филологического цикла (Татарский язык и литература)**

**1. Татар теленнән теоретик бирем. Түбәндә тәкъдим ителгән сорауга үз фикерегезне дәлилләп, җавап языгыз (15 балл).**

Татар телендә килеш категориясе: мәсьәләнең өйрәнү тарихы, килешләр системасы һәм килешләрнең грамматик мәгънәләре. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше.

**2. Текстны укыгыз һәм сорауларга җаваплар языгыз (15 балл).**

1) Әйе, Татарстанның йөрсәң йөреп туймастай, карасаң күреп туймастай соклангыч урыннары, чыннан да, бик күп. 2) Безнең республика мәсәлән яшел тугайлы болыннарга куе әрәмәле балыклы кош-кортлы агым суларга түгәрәк күлләргә бик бай. 3) Бездәге Мишә, Чирмешән, Зәй, Ык, Чишмә, Зөя, Кичү кебек агым суларны һәм шулардан бераз кечерәкләрне саный башласаң, аларның саны йөзгә җитәр. *(Гомәр Бәширов)*

а) Тексттан гидронимнарны язып алыгыз (5 б.)

ә) Икенче җөмләдә тиешле урыннарга тыныш билгеләрен куеп, җөмләне күчереп языгыз. (5 б.)

б) Өченче җөмләгә тулы синтаксик анализ ясагыз һәм схемасын төзегез (5 б.).

**3. Әдәбияттан теоретик бирем (15 балл).**

Образ һәм аның төрләре. Үз фикерләрегезне әсәрләрдән мисаллар аша дәлилләп языгыз.

**4. Әдәби иҗатка бәйле сорауга җавап языгыз (15 балл).**

М.Җәлилнең шагыйрь буларак иҗади йөзен (үзенчәлеген) билгели торган сыйфатлар дип, сез нинди үзенчәлекләрне атар идегез?

**5. Иҗади бирем – эссе. Бирелгән темаларның БЕРСЕН сайлап алып, 150 сүздән артмаган эссе языгыз (40 балл).**

1. Җирдә кеше торса торсын,

Эзе калсын тирән булып,

Үзе үлсә, эше калсын

Мең яшәрлек имән булып. (М.Җәлил)

2. Кеше китә – җыры кала... (М.Мәһдиев)

Әлеге шигырь юлларына һәм канатлы гыйбарәгә бәйле үзегезнең уйлануларыгыз, уй-фикерләрегез белән уртаклашыгыз.